# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 32 и $32^1$ Земельного кодекса Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
14 июля 2022 года

**Статья 1**

Внести в Земельный кодекс Республики Татарстан (в редакции Закона Республики Татарстан от 18 января 2005 года № 4-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 8 (II часть); 2005, № 1 (I часть), № 12 (I часть); 2006, № 7 (I часть); 2007, № 1 (I часть), № 4; 2008, № 5 (I часть); 2009, № 7 – 8 (III часть); 2010, № 11; 2011, № 11 (I часть); 2012, № 3, № 5 (I часть); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть), № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I); 2017, № 41 (часть I), № 52 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 22 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 60 (часть I); 2020, № 77 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 20 (часть I), № 29 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 3 (часть I), № 17 (часть I) следующие изменения:

1) в пункте 3 статьи 32:

а) подпункт 1 после слов «садоводства или огородничества» дополнить словами «, если такие граждане постоянно проживают на территории Республики Татарстан на протяжении пяти лет, предшествующих дню подачи заявления о предоставлении земельного участка, и состоят на учете в качестве нуждающихся в жилых помещениях, предоставляемых по договорам социального найма,»;

б) дополнить абзацем следующего содержания:

«Граждане, имеющие трех и более детей, считаются соответствующими предусмотренному подпунктом 1 настоящего пункта требованию о постоянном проживании на территории Республики Татарстан на протяжении пяти лет, предшествующих дню подачи заявления о предоставлении земельного участка, если хотя бы один из родителей или единственный родитель проживает на территории Республики Татарстан на протяжении пяти лет, предшествующих дню подачи заявления о предоставлении земельного участка.»;

2) в статье $32^1$:

а) в пункте 10:

дополнить подпунктами 8 и 9 следующего содержания:

«8) документ, подтверждающий, что заявитель состоит на учете в качестве нуждающегося в жилом помещении, предоставляемом по договору социального найма;

9) решение суда об установлении факта постоянного проживания заявителя на территории Республики Татарстан на протяжении пяти лет, предшествующих дню подачи заявления о предоставлении земельного участка (в случае отсутствия в паспорте заявителя отметки о его регистрации по месту жительства на территории Республики Татарстан на протяжении пяти лет, предшествующих дню подачи заявления о предоставлении земельного участка).»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«Документ, указанный в подпункте 8 настоящего пункта, запрашивается уполномоченным органом местного самоуправления самостоятельно, если заявитель не представил его по собственной инициативе.»;

б) в пункте 12:

после слов «представленные заявителем» дополнить словами «или полученные уполномоченным органом местного самоуправления»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«Извещение граждан об отказе во включении их в списки осуществляется не позднее семи дней со дня принятия уполномоченным органом местного самоуправления соответствующего решения заказным письмом с уведомлением о вручении либо путем вручения им извещения под роспись.»;

в) в пункте 13:

в абзаце первом слова «не позднее одного года с даты включения их в списки, за исключением случаев, предусмотренных пунктом 15 настоящей статьи» исключить;

в абзаце втором слова «процедуры выбора земельных участков» заменить словами «процедуры выбора земельного участка»;

г) в пункте 15:

подпункт 2 дополнить абзацем следующего содержания:

«д) снятия с учета в качестве нуждающихся в жилых помещениях, предоставляемых по договорам социального найма.»;

подпункт 4 изложить в следующей редакции:

«4) троекратного отказа граждан от выбора земельного участка на процедуре выбора земельного участка, либо троекратной неявки граждан на процедуру выбора земельного участка, либо, когда количество случаев отказа граждан от выбора земельного участка на процедуре выбора земельного участка и их неявки на процедуру выбора земельного участка в совокупности равно трем;»;

д) в пункте 17:

в абзаце первом слова «пунктом 10 настоящей статьи» заменить словами «подпунктами 1 – 7 пункта 10 настоящей статьи»;

абзац шестой изложить в следующей редакции:

«Документы, указанные в подпунктах 1 и 2 настоящего пункта, запрашиваются уполномоченным органом местного самоуправления самостоятельно, если заявитель не представил их по собственной инициативе.».

**Статья 2**

1. В отношении граждан, имеющих трех и более детей, которые до дня вступления настоящего Закона в силу подали заявление о предоставлении земельного участка, но решение о включении их в списки граждан, имеющих право на получение земельного участка для целей, указанных в подпункте 1 пункта 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан (далее – списки), не было принято, принятие данного решения, осуществление предусмотренной пунктом 15 статьи $32^1$ Земельного кодекса Республики Татарстан оценки соответствия граждан требованиям, указанным в пункте 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан, и предоставление земельного участка осуществляются без учета срока постоянного проживания граждан на территории Республики Татарстан и того, состоят ли они на учете в качестве нуждающихся в жилых помещениях, предоставляемых по договорам социального найма.

2. В отношении граждан, имеющих трех и более детей, которые до дня вступления настоящего Закона в силу были включены в списки, осуществление предусмотренной пунктом 15 статьи $32^1$ Земельного кодекса Республики Татарстан оценки соответствия граждан требованиям, указанным в пункте 3 статьи 32 Земельного кодекса Республики Татарстан, и предоставление земельного участка осуществляются без учета срока постоянного проживания граждан на территории Республики Татарстан и того, состоят ли они на учете в качестве нуждающихся в жилых помещениях, предоставляемых по договорам социального найма.

3. В отношении граждан, имеющих трех и более детей, которые до дня вступления настоящего Закона в силу подали заявление о предоставлении земельного участка, но решение о включении их в списки не было принято, а также граждан, имеющих трех и более детей, которые до дня вступления настоящего Закона в силу были включены в списки, абзац первый пункта 13 статьи $32^1$ Земельного кодекса Республики Татарстан применяется без учета изменений, внесенных настоящим Законом.

4. Положения подпункта 4 пункта 15 статьи $32^1$ Земельного кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) не применяются в отношении граждан, имеющих трех и более детей, которые до дня вступления настоящего Закона в силу были включены в списки. Указанные граждане исключаются из списков и им отказывается в предоставлении земельного участка в случае троекратного отказа граждан от выбора земельного участка на процедуре выбора земельного участка либо троекратной неявки граждан на процедуру выбора земельного участка.

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 30 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
25 июля 2022 года
№ 45-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 14 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяның 3 пунктында:

а) 1 пунктчада «индивидуаль торак» сүзләре алдыннан «әгәр мондый гражданнар җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәсәләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә торсалар,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнар, әгәр җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында ата-ананың берсе генә булса да яисә ялгыз ата йә ана Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәсә, әлеге пунктның 1 пунктчасында каралган җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү таләбенә туры килә дип санала.»;

2) 32[1] статьяда:

а) 10 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктчалар өстәргә:

«8) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәптә торуын раслаучы документ;

9) мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турындагы суд карары (мөрәҗәгать итүченең паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында аны Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәү билгесе булмаган очракта).»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның 8 пунктчасында күрсәтелгән документ, мөрәҗәгать итүче аны үзе тапшырмаган булса, вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.»;

б) 12 пунктта:

«мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган» сүзләреннән соң «яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан алынган» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гражданнарга аларны исемлекләргә кертүдән баш тарту турында хәбәр вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып җиде көннән дә соңга калмыйча тапшырылуы хакында хәбәр ителә торган заказлы хат белән җибәрелә йә аларга имза куйдырып тапшырыла.»;

в) 13 пунктта:

беренче абзацта «, әлеге статьяның 15 пунктында каралган очраклардан тыш, аларны исемлекләргә керткән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын» сүзләрен «җир кишәрлеген сайлап алу процедурасын» сүзләренә алмаштырырга;

г) 15 пунктта:

2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«д) социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә торудан төшереп калдыру.»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) гражданнар җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тартса, йә гражданнар җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килми калса, йә гражданнарның җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында җир кишәрлеген сайлап алудан баш тарту һәм аларның җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына килми калу очраклары барысы бергә өчкә тигез булса;»;

д) 17 пунктта:

беренче абзацта «әлеге статьяның 10 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 10 пунктындагы 1 – 7 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, мөрәҗәгать итүче аларны үзе тапшырмаган булса, вәкаләтле җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр җир кишәрлеге бирү турында гариза тапшырган, әмма аларны Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлеге алу хокукы булган гражданнар исемлекләренә (алга таба – исемлекләр) кертү турында карар кабул ителмәгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга карата мондый карарны кабул итү, гражданнарның Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясындагы 15 пунктында каралган бәяләүне гамәлгә ашыру һәм җир кишәрлеген бирү гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү срогын һәм аларның социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә тору-тормавын исәпкә алмыйча башкарыла.

2. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр исемлекләргә кертелгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга карата гражданнарның Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясындагы 15 пунктында каралган бәяләүне гамәлгә ашыру һәм җир кишәрлеген бирү гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү срогын һәм аларның социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә тору-тормавын исәпкә алмыйча башкарыла.

3. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр җир кишәрлеге бирү турында гариза тапшырган, әмма аларны исемлекләргә кертү турында карар кабул ителмәгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга, шулай ук әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр исемлекләргә кертелгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга карата Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясындагы 13 пунктының беренче абзацы әлеге Закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алмыйча кулланыла.

4. Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясындагы 15 пунктының 4 пунктчасы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр исемлекләргә кертелгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга карата кулланылмый. Күрсәтелгән гражданнар исемлекләрдән төшереп калдырыла һәм аларга, гражданнар җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тартса йә гражданнар җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килми калса, җир кишәрлеге бирүдән баш тартыла.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 30 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 июль
№ 45-ТРЗ